| | | |
|---|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 142 от “05” 03 2019 года

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы
Башкарма комитеты карары

Спас муниципаль районы халкын һәм территориясен
гадәттән тыш хәлләрдән саклау буенча
мәгълүмат туплау һәм мәгълүмат алмашу турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Россия Федерациясендә халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау буенча мәгълүмат туплау һәм мәгълүмат алмашу турында” 1997 елның 24 мартында кабул ителгән карары нигезендә, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән кисәтү, халыкка көтеләчәк һәм инде килеп чыккан гадәттән тыш хәлләр турында вакытында белгертү максатында чыгарылган

К А Р А Р:

1. Спас муниципаль районында халыкны табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау буенча мәгълүмат туплау һәм мәгълүмат алмашу Тәртибен (1нче кушымта) расларга.
2. Спас муниципаль районы территориясендә урнашкан министрлык һәм ведомстволарның территориаль вәкиллекләре, җирле үзидарә органнарына, төрле милектәге предприятие, оешма җитәкчеләре халыкны табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау буенча мәгълүмат белән тәэмин итәргә тиеш.
3. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземә йөклим.

ТР Спас муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе В.А.Осокин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СПАССКОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ИНН 1637005464

Татарстан Республикасы Спас муниципаль
Районы Башкарма комитеты карарының
1нче кушымтасы.
“____” _________ 2019 ел. №___

Спас муниципаль районы халкын һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау буенча мәгълүмат туплау һәм мәгълүмат алмашу

ТӘРТИБЕ

1. Әлеге карар нигезендә Спас муниципаль районы халкын һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау буенча мәгълүмат туплау һәм мәгълүмат алмашуның төп Тәртибе (аннары – мәгълүмат) билгеләнә.

Мәгълүматта табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлнең көтеләчәге һәм инде булганлыгы турында (аннары – гадәттән тыш хәл), бу хәлнең китергән нәтиҗәләре, халыкны һәм территорияләрне саклау буенча чаралар, авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләрне алып бару, гадәттән тыш хәлне бетерүдә катнашучы кешеләр һәм техника, тиешле объект һәм территорияләрдә радиация, химик, медик-биологик, шартлау, янгын чыгу куркынычы һәм экологик хәл турында тиешле белешмәләр, шулай ук халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өчен башкарма властьның федераль органнары, атом энергиясе буенча “Росатом” Дәүләт корпорациясе, космик эшчәнлек буенча “Роскосмос” Дәүләт корпорациясе, Россия Федерациясе субъектларының башкарма власть органнары, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча структураларның составы, көче һәм чаралары, шул исәптән даими әзерлектә торучы көчләр, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү өчен финанс һәм материаль ресурслардан файдалану һәм аларны тулыландырып тору турында барысы да төгәл күрсәтелергә тиеш.

2. Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгуны кисәтү һәм инде килеп чыккан очракларда аның нәтиҗәләрен бетерү, шулай ук халыкка гадәттән тыш хәл килеп чыгачагы турында алдан белгертү һәм инде килеп чыккан очракта аның нәтиҗәләрен бетерү буенча тиешле чаралар күрү өчен мәгълүматлар җыю һәм алмашу белән Спас муниципаль районы оешмалары, җирле үзидарә органнары, дежур-диспетчерлык хезмәтләре шөгыльләнә.
3. Җирле үзидарә органнары, предприятие һәм оешмалар халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өчен вәкаләтле булган махсус органнар – Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы (аннары – Татарстан Республикасы МЧСы) һәм Спас муниципаль районының янгын сүндерү-коткару часте белән мәгълүматлар туплый һәм мәгълүмат алмаша.
4. Спас муниципаль районының янгын сүндерү-коткару часте:

- мәгълүмат туплау һәм мәгълүмат алмашу буенча эшне координацияли;
- Спас муниципаль район территориясендә урнашкан һәм тирә-як мохитның торышына контрольлек итүче һәм куркыныч объектлардагы хәлне күзәтеп торучы федераль буйсынудагы структур органнардан һәм әлеге объектлар тирәсендә урнашкан Спас муниципаль районы җирле үзидарә органнарыннан алынган мәгълүматларны туплый һәм эшкәртә;

- Спас муниципаль районы Башкарма комитетына һәм Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау эшенең ничек оештырылуы турында еллык доклад өчен мәгълүмат тапшыра;
- гадәттән тыш хәлләрнең учетын алып бара.

5. Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау турындагы мәгълүмат түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

- гадәттән тыш хәлләрнең (булачак хәлнең) нинди куркыныч тудыруы һәм китереп чыгарачак нәтиҗәләре;
- радиация, химия, медик-биологик хәлнең торышы, шартлау, янгын чыгу куркынычы һәм экология хәленең торышы;
- гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм булдырмау өчен тәкъдим ителә торган чаралар;
- гадәттән тыш хәлнең фактлары һәм төп параметрлары;
- халыкны һәм территорияләрне саклау чаралары, гадәттән тыш хәл булган урында коткару эшләре һәм башка кичектергесез чаралар турында;
- оешмаларның эшчәнлек характеры һәм аларга яный торган куркыныч турында.

6. Мәгълүмат гамәлдә булган барлык каналлар һәм элемтә төрләре, шул исәптән электрон почта аша тапшырылырга мөмкин.
7. Гадәттән тыш хәл чыгу ихтималы һәм бу хәлнең килеп чыгу фактлары турындагы гадәттән тыш мәгълүмат Спас муниципаль районындагы янгын сүндерү-коткару частенең оператив-дежурлык хезмәте аша тиз арада алар карамагында булган элемтә чаралары ярдәмендә махсус парольләр кулланып (телефон буенча “БЕДСТВИЕ”, телеграф буенча – “ШТОРМ”) тапшырыла.
8. Гадәттән тыш хәл чыгу турында мәгълүматлар, шулай ук ашыгыч һәм агымдагы хәбәрләр идарә органнары җитәкчеләре имзасы белән раслана.
9. Спас муниципаль районының янгын сүндерү-коткару часте тиешле мәгълүматларны соратып алу һәм алардан файдалану хокукы бирелә.
10. Спас муниципаль районындагы янгын сүндерү-коткару частенең оператив дежурные гадәттән тыш хәл янавы яки бу хәлнең килеп чыгу турында мәгълүмат алган очракта, ул бу мәгълүматны Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының оператив дежерныена (тел. 843 291-57-97, 272-99-04, 12-91), Спас муниципаль районының гадәттән тыш хәлләр һәм янгын иминлеге буенча Комиссия рәисенә, министрлыклар һәм ведомстволарның территориаль вәкиллекләренә җиткерә. Шулай ук Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының күрше районнардагы идарәләренә да тапшыра ала.